**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**26.07.2019** **№ 1158**

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының “Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү турында” 2019 ел, 30 нчы апрель, 592 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында**

“Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексы”, 2006 ел, 19 нчы декабрь, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында”, 2010 ел, 30 нчы июль, 60-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затларның исемлеген кушымта нигезендә түбәндәге редакциядә билгеләргә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Афанасьев А.П. ка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Кушымта
Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты карарына
26.07.2019 № 1158

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы территориясендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге**

| N т/б | Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексы статьялары исемлеге (алга таба – ТР КоАП) | Вазыйфаи затлар исемлеге |
|---|---|---|
| 1 | ТР КоАПның 2.1 статья.<br>Татарстан Республикасы телләре турындагы законнарны бозу.<br>Юл һәм башка күрсәткечләр һәм билгеләнүләрне, адреслы атрибутика, башка визуаль мәгълүматны рәсмиләштергәндә һәм урнаштырганда телләр турында Татарстан Республикасы законнары таләпләрен тотмау, шулай ук гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен бозуга яисә тел буенча гражданнарның хокукларын чикләүгә китерә торган телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу – вазыйфаи затларга кисәтү ясау һәм биш йөз сумнан мең сумга кадәр административ штраф каралган. | - Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 2 | 2.4 статья.Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр кылу.<br><br>Татарстан Республикасы Дәүләт гербына яки Дәүләт флагына карата мыскыллау язуларын төшерүдә, зыян күрүдә, юкка чыгаруда, яисә Дәүләт гербын, Дәүләт флагын, Татарстан Республикасы Дәүләт гимнын аларга карата ачык булмаган ысуллар белән куллану, шулай ук аларны билгеләнгән кагыйдәләрне бозып куллану – гражданнарга өч йөз сумнан биш йөз сумга кадәр: вазыйфаи затларга – биш йөз сумнан мең сумга кадәр админстратив штраф салу каралган. | - Советның оештыру бүлеге начальнигы (килешү буенча);<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 3 | 2.5. статья. Татарстан Республикасы | - Советның оештыру бүлеге начальнигы |

| | | |
|---|---|---|
| | дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яки йөртү<br>1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре кебек яки алар белән охшашлык булган бүләкләрне әзерләү һәм йөртү –<br>өч йөз сумнан биш йөз сумга кадәр админстратив штраф салу каралган.<br>2. Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен йөртергә хокукы булмаган затлар тарафыннан йөртү –<br>йөз сумнан өч йөз сумга кадәр админстратив штраф салу каралган. | (килешү буенча);<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 4 | 2.6 статья. Җирле үзидарә органнары муниципаль хокукый актларын үтәмәү.<br>1. Җирле үзидарә органнарының үз вәкаләтләре кысларында кабул иткән, әлеге Кодексның 2.7, 2.8, 3.2-3.7 статьяларындагы очраклардан кала, муниципаль хокукый актларын үтәмәү – кисәтү ясау һәм гражданнарга бер мең сумнан ике мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – унбиш мең сумнан утыз мең сумга кадәр; юридик затларга ике йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр административ штраф салу каралган.<br>2. Бер ел дәвамында кабаттан эшләнгән шул ук гамәлләр –<br>гражданнарга ике мең биш йөз сумнан биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – утыз мең сумнан илле мең сумга кадәр; юридик затларга биш йөз мең сумнан миллион сумга кадәр административ штраф салу каралган. | - Башкарма комитет эшләре белән идарә итүче;<br>- Советның баш белгеч-юристы (килешү буенча);<br>- Советның оештыру бүлеге начальнигы (килешү буенча);<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 5 | 2.7. статья. Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларын куллану тәртибен бозу.<br>Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларын куллану тәртибен бозу – кисәтү ясау яки вазыйфаи затларга йөз сумнан мең сумга кадәр админстратив штраф салу каралган. | - Советның оештыру бүлеге начальнигы (килешү буенча);<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 6 | ТР КоАПның 2.8 статьясы<br>Өй шартларында җитештерелгән составында этил спирты булган продукцияне сату һәм (яки) акчага әйләндерү. | - Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары;<br>- Башкарма комитетның икътисад бүлеге начальнигы, белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ |

| | | |
|---|---|---|
| | | баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 7 | 2.8. статья. Өй шартларында җитештерелгән составында этил спирты булган продукцияне сату һәм (яки) акчага әйләндерү.<br>Өй шартларында җитештерелгән составында этил спирты булган продукцияне сату һәм (яки) акчага әйләндерү –<br>гражданнарга өч йөз меңнән биш меңгә кадәр күләмдә административ штраф салу каралган. | - Биектау муниципаль районы Советының ришвәтчелеккә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе (килешү буенча);<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 8 | 2.12. статья. Гражданнарны социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен бозу.<br>Гражданнарны социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен бозу, шулай ук үзе белән гражданнарны исәпкә куюдан хокуксыз баш тартуга яисә гражданнарны исәптән алуга китергән, күрсәтелгән исәп алып бару тәтибен бозу –<br>вазыйфаи затларга биш мең сумнан сигез мең сумга кадәр административ штраф салу каралаган. | - Биектау муниципаль районы Советының ришвәткә каршы тору мәсьәләләре буенча Башлык ярдәмчесе (килешү буенча);<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 9 | 2.14. статья. Тартмый торган тәмәке әйберләре белән Татарстан Республикасы территориясендә күпләп һәм ваклап сәүдә итүне тыюны бозу.<br>Тартмый торган тәмәке әйберләре белән Татарстан Республикасы территориясендә күпләп һәм ваклап сәүдә итүне тыюны бозу –<br>гражданнарга - бер мең сумнан ике мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – өч мең сумнан дүрт мең сумга кадәр; юридик затларга – егерме мең сумнан утыз мең сумга кадәр административ штраф салу каралган. | - Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары;<br>- Башкарма комитетның икътисад бүлеге начальнигы, белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 10 | 2.15. статья. Терроризмны профилактикалау, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) | - Террорчылыкка каршы тору комиссиясе сәркатибе;<br>- Башкарма комитетның төзелеш, |

| | | |
|---|---|---|
| | бетерү буенча коллегиаль орган карарын үтәмәү яки бозу.<br>1. Терроризмны профилактикалау, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү буенча, Россия Федерациясе Президенты карары белән терроризмны профилактикалау буенча, федераль башкарма хакимият органының территориаль органнары, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеген координацияләү максатыннан формалашытырлаган коллегиаль орган карарын үтәмәү яки бозу, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү (алга таба әлеге статьяда – терроризмны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы органы) –<br>гражданнарга – өч мең сум; вазыйфаи затларга – егерме мең сум; юридик затларга – илле мең сум административ штраф салу каралган.<br><br>2. Терроризмны профилактикалау, шулай ук аның нәтиҗәләрен минимальләштерү һәм (яки) бетерү буенча коллегиаль орган тарафыннан аның компетенциясе чикләрендә кабул ителгән, терроризмны профилактикалау буенча Татарстан Республикасы органы җиткәчесе карары белән формалаштырылган карарны бер муниципаль берәмлек территориясендә яки Татарстан Республикасының берничә муниципаль берәмлеге территриясендә үтәмәү яки бозу гражданнарга – бер мең сумнан өч мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – биш мең сумнан ун мең сумга кадәр; юридик затларга – утыз мең сумнан илле мең сумга кадәр административ штраф салу каралган. | архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 11 | 3.2. статья Урамда сату итүне оештыру тәртибен бозу.<br>1.Сату өчен билгеләнмәгән урыннарда сату алып бару, әлеге статьяның 3 бүлеге белән күздә тотылган очраклардан кала – кисәтү ясау һәм гражданнарга – бер меңнән өч мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – биш мең сумнан ун мең сумга кадәр; юридик затларга – егерме мең сумнан илле мең сумга кадәр административ штраф салу каралган. | - Башкарма комитетның икътисад бүлеге начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |

| | | |
|---|---|---|
| | 2. Әлеге статьяның 1 бүлеге белән күздә тотылган гамәлләрне кабаттан башкару – гражданнарга –<br>өч мең сумнан биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – ун мең сумнан егерме мең сумга кадәр; юридик затларга – йөз илле мең сумнан ике йөз мең сумга кадәр административ штраф салу каралган.<br><br>3. Стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен (схемасын) бозу –<br>кисәтү ясау һәм гражданнарга – өч мең сумнан дүрт мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – ун мең сумнан унбиш мең сумга кадәр; юридик затларга – йөз мең сумнан йөз илле мең сумга кадәр административ штраф салу каралган.<br><br>4. Әлеге статьяның 3 бүлеге белән күздә тотылган гамәлләрне кабаттан башкару – гражданнарга –<br>дүрт мең сумнан биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга – егерме мең сумнан утыз мең сумга кадәр; юридик затларга – ике йөз мең сумнан өч йөз мең сумга кадәр административ штраф салу каралган. | |
| 12 | 3.3 статья Җир асты коммуникацияләрен карап тоту кагыйдәләрен бозу.<br>Телефон, җылылык, су үткәрү, газ, канализация коеларын, яңгыр сулары җыю һәм җәяүлеләрнең тормышына һәм сәламәтлегенә, транспорт йөрешенә куркыныч тудыручы чикләүче коймаларны карап тоту кагыйдәләрен бозу –<br>вазыйфаи затларга бер мең сумнан ике мең биш йөз сумга кадәр; юридик затларга – биш мең сумнан егерме мең сумга кадәр административ штраф салу каралган. | - Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм ТКХ буенча урынбасары;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 13 | 3.4 статья. Урам, квартал эчендәге урам утларын карап тоту кагыйдәләрен бозу.<br>Урам, квартал эчендәге урам утларының булмавы яки аларны төзексез рәвештә тоту –<br>вазыйфаи затларга бер мең сумнан ике мең биш йөз сумга кадәр; юридик затларга – биш мең сумнан егерме мең | - Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |

| | | |
|---|---|---|
| | сумга кадәр административ штраф салу каралган. | |
| 14 | 3.5 статья. Тышкы мәгълүматны урнаштыру тәртибен бозу.<br>1. Элмә такталарны, белдерүләрне, листовкаларны һәм башка тышкы мәгълүматны әлеге максатлар өчен булмаган урыннарда урнаштыру –<br>кисәтү ясау һәм гражданнарга бер мең сум; вазыйфаи затларга унбиш мең сумнан егерме мең сумга кадәр; юридик затларга – унбиш мең сумнан егерме биш мең сумга кадәр административ штраф салу каралган.<br>2. Бер ел дәвамында эшләнгән шул ук гамәлләр –<br>гражданнарга ике мең биш йөз сумнан өч мең биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга утыз мең сумнан кырык мең сумга кадәр; юридик затларга – илле мең сумнан йөз мең сумга кадәр административ штраф салу каралган. | - Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 15 | 3.6 статья. Җирлек һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерү, калдыклар белән эш итү муниципаль кагыйдәләрен бозу<br>1. Җирлек һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен, әлеге Кодексның 3.17 статьясы белән каралган очраклардан кала, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу –<br>кисәтү ясау һәм гражданнарга ике мең сумнан өч мең биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга унбиш мең сумнан утыз мең сумга кадәр; юридик затларга – ике йөз мең сумнан биш йөз мең сумга кадәр административ штраф салу каралган.<br><br>2. Бер ел дәвамында эшләнгән шул ук гамәлләр –<br>гражданнарга өч мең биш йөз сумнан биш мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга утыз мең сумнан илле мең сумга кадәр;<br>юридик затларга – биш йөз мең сумнан миллион сумга кадәр административ штраф салу каралган. | - Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |

| | | |
|---|---|---|
| 16 | 3.7 статья. Этләрне йөртү тәртибен бозу. Урамнарда, паркларда, скверларда, барлык төр җәмәгать траспортында муенчаклы баусыз һәм борынчыксыз этләр белән булу, аларны җәмәгать урыннарында караусыз калдыруга тиң – өч йөз сумнан мең сумга кадәр админстратив штраф салу каралган. | - Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 17 | 3.8 статья. Төнге вакытта гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозу.<br>1. Төнге вакытта гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозу –<br>кисәтү ясау һәм гражданнарга биш йөз сумнан мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга биш мең сумнан ун мең сумга кадәр; юридик затларга – егерме мең сумнан илле мең сумга кадәр административ штраф салу каралган.<br>2. Бер ел дәвамында эшләнгән шул ук гамәлләр –<br>гражданнарга бер мең биш йөз сумнан ике мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга унбиш мең сумнан егерме мең сумга кадәр; юридик затларга – алтмыш мең сумнан җитмеш мең сумга кадәр административ штраф салу каралган. | - Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 18 | 3.10 статья. ТР территориясендәге су объектларында кешеләрнең тормышын саклау кагыйдәләрен бозу.<br>1. ТР территориясендәге су объектларында кешеләрнең тормышын саклау кагыйдәләрен бозу, әлеге статьяның 2 бүлеге белән каралган очраклардан кала –<br>кисәтү ясау һәм гражданнарга бер мең сумнан бер мең биш йөз сумга кадәр; вазыйфаи затларга дүрт мең сумнан биш мең сумга кадәр; юридик затларга – кырык мең сумнан илле мең сумга кадәр административ штраф салу каралган.<br>2. Боз калынлыгы 7 сантиметрдан да ким булганда су объетларындагы бозга чыгу һәм (яки) керү –<br>кисәтү ясау һәм гражданнарга бер мең биш йөз сумнан ике мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга биш мең сумнан җиде мең сумга кадәр; юридик затларга – илле мең сумнан җитмеш мең сумга кадәр административ штраф салу каралган. | - Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |

| | | |
|---|---|---|
| 19 | 3.11 статья. Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү чараларын тәэмин итүгә таләпләрне бозу.<br>1. Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның физик, интеллектауль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү буенча Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән чаралар белән тәэмин итү таләпләрен тотмау –<br>кисәтү ясау һәм гражданнарга биш йөз сумнан бер мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга өч мең сумнан биш мең сумга кадәр; юридик затларга – унбиш мең сумнан егерме мең сумга кадәр административ штраф салу каралган.<br>2. Бер ел дәвамында эшләнгән шул ук гамәлләр –<br>гражданнарга ике мең сум; вазыйфаи затларга унбиш мең сум; юридик затларга –илле мең сум административ штраф салу каралган. | - Опека һәм попечительлек буенча бүлек начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 20 | 3.14 статья. Мәдәни-күңел ачу чараларында булганда җәмәгать тәртибен бозу.<br>1. Мәдәни-күңел чаралары уздырган вакытта, тамашачыларның үзлекләреннән спорт мәйданчыгына, уен кырына, йөгерү юлына, манежга, сәхнәгә (шул исәптән боздагы сәхнәгә) чыгуы –<br>гражданнарга биш йөз сумнан бер мең сумга кадәр административ штраф салу каралган.<br>2. Бер ел дәвамында әлеге статьяның 1 бүлеге белән күздә тотылган гамәлләр –<br>гражданнарга бер мең сумнан өч мең сумга кадәр административ штраф салу каралган.<br>3. Трибунага, спорт мәйданчыгына, уен кырына, йөгерү юлына, манежга, сәхнәгә (шул исәптән боздагы сәхнәгә), су объекты акваториясенә мәдәни-күңел ачу чараларын уздыруга комачау итә торган чит предметлар ату –<br>гражданнарга бер мең сумнан ике мең сумга кадәр админстратив штраф салу каралган.<br>4. Бер ел дәвамында әлеге статьяның 3 бүлеге белән күздә тотылган гамәлләр –<br>гражданнарга өч мең сумнан биш мең сумга кадәр административ штраф салу | - Башкарма комитетның мәдәният бүлеге начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |

| | | |
|---|---|---|
| | каралган. | |
| 21 | 3.15 статья. Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү.<br>1. Теләнү, күрәзә итү, җенси характердагы хезмәтләр күрсәтү максатыннан, җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнүдә чагылган җәмәгать тәртибен бозу –<br>кисәтү ясау һәм йөз сумнан биш йөз сумга кадәр админстратив штраф салу каралган.<br>2. Бер ел дәвамында кабаттан эшләнгән шул ук гамәлләр –<br>өч мең сумнан биш мең сумга кадәр админстратив штраф салу каралган. | - Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 22 | 3.16 статья. Түләүле муниципаль машина кую урынында (парковка урыннары) транспорт чараларын куйган өчен түләмәү.<br>Түләүле муниципаль машина кую урынында (парковка урыннары) транспорт чараларын куйган өчен түләмәү –<br>ике мең биш йөз сум күләмендә админстратив штраф салу каралган.<br>Искәрмә. Әлеге статьяда түләүле муниципаль машина кую урыны (парковка урыннары) дигәндә вәкаләтле орган карары буенча түләүле нигездә транспорт чаралары кую урынын оештыру өчен тәгаенләнгән, территорияне төзекләндерү элементы (төзекләндерү объекты) буларак махсус билгеләнгән һәм кирәк булган очракта җиһазландырылган, шул ук вакытта җирле әһәмияткә ия гомуми кулланылышта булган автомобиль юлының бер өлеше булган һәм (яки) йөри торган өлешкә һәм (яки) тротуарга, юл кырына, эстакадага яки күпергә яки эстакада асты яки күпер асты урыннарының бер өлешенә, мәйданнарга һәм башка урам-юл челтәрләре объектларына, биналарга яки корылмаларга килеп тоташкан урын күздә тотыла. | - Башкарма комитет җитәкчесенең төзелеш, архитектура һәм ТКХ буенча урынбасары;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 23 | 3.17 статья. Торак пунктларының яшелләндерелгән территорияләре чикләрендә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннарны йөртү өчен мәйданчыкларда, шулай ук өй яны территориясендә урнашкан хуҗалык | - Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече; |

| | | |
|---|---|---|
| | мәйданчыкларында транспорт чараларын кую.<br>Торак пунктларының яшелләндерелгән территорияләре чикләрендә (газоннарны, чәчәклекләрне һәм чирәмле үсемлекләр булган башка территорияләрне кертеп), балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннарны йөртү өчен мәйданчыкларда, шулай ук өй яны территориясендә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында транспорт чараларын кую –<br>гражданнарга ике мең сумнан өч мең сумга кадәр; вазыйфаи затларга биш мең сумнан егерме мең сумга кадәр; юридик затларга – илле мең сумнан йөз мең сумга кадәр административ штраф салу каралган.<br>Искәрмә. Әлеге статьяның нигезләмәләре хокукка каршы эшләрне, авария, табигать бәла-казаларын, башка гадәттән тыш хәлләрне, янгыннарны сүндерү, ашыгыч эшләр башкару, гражданнарның куркынычсызлыгын тәэмин итү яки халыкның яшәешен тәэмин итү объектлары эшчәнлеге белән бәйле, оброна чараларын башкару (шул исәптән гражданнар оборонасы һәм мобилизация), оборона сәләтен ныгыту һәм дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итү, җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать куркынычсызлыгын саклау, гражданнарны коткару, аларның гомеренә яки сәламәтлегенә куркынычны бетерүгә юнәлдерелгән юридик затларның һәм гражданнарның гамәлләренә кагылмый. | - “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 24 | 4.4 статья. Муниципаль милектә булган торак булмаган фонд объекты белән идарә итү тәртибен бозу, һәм әлеге объектны куллану.<br>1. Муниципаль милектә булган торак булмаган фонд объекты белән идарә итү тәртибен бозу, һәм әлеге объектны куллану –<br>вазыйфаи затларга кырык меңнән илле меңгә кадәр күләмдә админстратив штраф салу каралган<br>2. Үз көчен югалтты. | - Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы;<br>- Милек һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисе;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 25 | 5.1 статья. Билетсыз йөрү.<br>Автомобиль һәм гомуми кулланылыштагы | - Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы; |

| | | |
|---|---|---|
| | шәһәр электр транспортында билетсыз йөрү –<br>өч йөз сум күләмендә админстратив штраф салу каралган. | - “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 26 | 5.2 статья. Багаж ташу кагыйдәләрен бозу. Автомобиль һәм гомуми кулланылыштагы шәһәр электр транспортында багажны түләмичә йөртү –<br>өч йөз сум күләмендә админстратив штраф салу каралган. | - Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |
| 27 | 5.6 статья. Пассажирны йөртүдән баш тарту<br>Социаль йөртү документы булган пассажирны йөртүгә, автомобиль һәм гомуми кулланылыштагы шәһәр җир өсте электр транспортында тышкы якта яки эчтә әлеге категория гражданнарга йөртүгә язмача тыю урнаштыру юлы белән тоткарлык тудырган гамәл, яки йөртүченең һәм (яки) кондукторның тиешле итеп рәсмиләштерелгән йөртү документларын кабул итүдән баш тартуы, социаль йөртү документы булган пассажирны йөртүгә телдән тыю, физик тәэсир итү яки башка тоткарлык тудыруга тиң –<br>гражданнарга бер мең сум; вазыйфаи затларга өч мең сумнан биш мең сумга кадәр; юридик затларга – унбиш мең сумнан егерме мең сумга кадәр административ штраф салу каралган.<br>Икенче өлеш үз көчен югалтты. | - Башкарма комитетның төзелеш, архитектура һәм ТКХ бүлеге начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ начальнигы;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ баш белгече;<br>- “Административ-техник инспекция” МКУ әйдәп баручы белгече. |